БЕРКЕТМӘ

ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕННӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ БУЕНЧА АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР

07 июнь 2019 ел

Иске Чүриле авылы 10 сәг. 00 мин.

Үткәрү урыны: Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты

45 кеше катнаша

Галиева Н.Х.: Хәерле көн, Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы урынбасарының 2019 елның 26 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә бездә бүген Иске Чүриле авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрелә.

Ачык тыңлауларны үткәрү өчен җаваплы итеп – Гарифуллин Р.Х. билгеләнде, 4 нче сайлау округы депутаты Иске Чүриле урта мәктәбе укытучысы.

Секретаре: Сафиуллин А.Х. — Иске Чүриле 1 нче сайлау округы буенча депутат, Иске Чүриле урта мәктәбе операторы

Иске Чүриле авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-34 статьялары, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә башланды.

Ачык тыңлаулар датасы һәм кагыйдәләр, карарлар проекты турында мәгълүмат Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, авыл җирлегенең торак пунктлары стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган иде: 422014, Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52; 422014, Татарстан Республикасы, Арча районы, Штерә авылы, Совет ур., 30б.

Иске Чүриле авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар түбәндәге адрес буенча үткәрелә: 422014, Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт. Ачык тыңлаулар башланганчы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге ПЗЗ проекты буенча язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр килмәде. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге ПЗЗ проекты буенча язма һәм телдән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү сроклары 2019 елның 6 апреленнән 6 июненә кадәр. Шулай ук бернинди кисәтүләр һәм тәкъдимнәр дә булмады.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау өчен шартлар тудыру максатларында эшләнә, шәһәр төзелешен зоналаштыруга керә. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү яңа Генераль планны раслау, РФ Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре түбәндәгеләрне үз эченә ала: аларны куллану һәм әлеге кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе; шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы; шәһәр төзелеше регламентлары.

Галиева Н. Х.: сораулар бармы? Ачык тыңлаулар уздыру барышында кисәтүләр булмады, кергән тәкъдим игътибарга алыначак. Әгәр сораулар юк икән, халык алдында тыңлаулар булды дип санала.

Ачык тыңлауларны үткәрү
өчен җаваплы: Гарифуллин Р.Х.

Секретаре: Сафиуллин А.Х.